# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 3** **10.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Әмәкәй авыл җирлеге составына керүче
Иске Әлмәт торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Иске Әлмәт торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1700 (бер мең җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Иске Әлмәт авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Иске Әлмәт авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, Иске Әлмәт авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Иске Әлмәт авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- Иске Әлмәт авылы җирлеген төзекләндерүне оештыруга;
- Әмәкәй авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүгә, Иске Әлмәт авылы суларын чыгаруны оештыруга;
- Иске Әлмәт авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Иске Әлмәт авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Иске Әлмәт авылы, Ленин урамы борылышы, 2 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы И.И.Шакирҗанова.